КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 февраль г.Казань № 129

2022 елга Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына торак урыны наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында» 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган Торак урыннары наемы шартнамәләре буенча торак алучылар исемлеген төзү һәм раслау тәртибенең 14 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2022 елга Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларына торак урыны наемы шартнамәсе буенча бирелә торган торак төзү буенча муниципаль районнарның чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтүгә субсидияләр күләмен исәпләп чыгару өчен Татарстан Республикасы авыл территорияләрендә гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясен 42 400,0 сум күләмендә расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин